**Бәкер Кәбир**

# ТУКАЙ ПЕТЕРБУРГТА

Бүген сөекле халык шагыйре Габдулла Тукаевның вафатына бер ел тулды... Вафатыннан бер ел элек иде әле, 1912 нче елның апрель егермеләрендә Тукай мәрхүм – алланың рәхмәтендә булсын – Петербургка килде. Шуңа кадәр туган авылы – Казан – Урал каласы – Әстерхан вә бер мәртәбә иттифакый тугры килеп барган Мәкәрҗә ярминкәсеннән башка бер җиргә чыкмаган Тукайның Петербурга килүе иттифакый түгел. Ахыр сулышына кадәр бу яшь татар талантының исеменнән файдаланырга теләүчеләр Петербургта да табылмый калмадылар... 1912 нче елның алдында Петербургта бер кыйсем яшь дини голәма арасында «Хәбәр» исемендә бер газета чыгару фикере таралды. Шул вакыт Муса әфәнде Бигиев Казанга Тукайны чакырып хат язган. Ул вакыт Тукай бу хатка, ни өчендер, иҗабәт итмәгән. Яз булгачтан, дәваланырга тугры килеп, шул уңайдан Петербургка да барып китәргә уйлаган. Яз көне, апрельнең 20 ләрендә, ничәнче көн икәне ачык хәтеремдә түгел, бервакыт Петербургта польский столовойлардан берендә ашап утырсам, иптәшләрдән бере миңа:

– Ишеттеңме?.. Бик яңа бер хәбәр бар, Тукай Петербурга килгән диләр, – диде.

Шул ук хәбәрне Петербург җәмгыяте хәйриясе мәктәбенең мөдире имам Лотфулла әфәнде Исхаковтан да ишеттем.

*Иттифакый – очраклы рәвештә.*
*Бер кыйсем – бер төркем.*
*Иҗабәт итмәгән – кабул итеп җавап бирмәгән.*

Ул, Тукайның килгәненә 3–4 көн булып, борынгы иптәшләренең күрешергә килмәүләреннән зарланганлыгын сөйләде вә билхасса мине сорашып, янына барып чыгуымны теләгәнлеген белдерде:

– Үзе авыру, хәл эчендә генә ята, бер кайда чыгаалмый, беткән инде бичара. Чак җаны да, чак җүне, – диде.

Кичен без Кәрим Сәгыйть әфәнде белән янына – Сергеевский урамда Муса әфәнденең квартирына бардык. Без барганда кеше юк, Тукай чишенгән, эчке киеменнән генә кроватька бөкрәеп яткан иде. Бик кечкенә бер вөҗүд, аның өстенә, бөкрәйгәч тә, бик «нәни» булып калган. Ишектән керү белән күрешкәч тә, Тукайның авырганын элек бер дә күрмәгән, белмәгән кебек:

– Авырыйсыңмыни? – дидек.

– Юк, менә әле яңа гына Муса әфәнде кереп: «Петербург гали мәктәпләрендә укый торган курсистка туташлар килгәннәр, сезне күрергә телиләр» дип котны алды, бәла... ничек тә котылырга белмәгәч, авырдым. Гениальный бер хәйлә... «Авырый, чишенеп яткан дипәйтеңез» дидем. Ялган булмасын өчен менә инде 2–3 сәгатьтән бирле чишенеп, авырып ятамын, – диде.

Тукайда һәрвакыт авыруга сер бирмәскә тырышу бәлиясе бар иде. Үлгәнче ул шул бәласеннән котыла алмады шикелле. Фәкать хәл аңа карап яшерен түгел иде. Көчкә хәл

алып, минут саен әллә ничә мәртәбә йөткереп, вакыты-вакыты илә тотлыгып, тын ала алмый тора иде. Шулай да без кергәчтән куанып күтәрелеп киткән кебек булды. (Аңа кадәр иркенләп сөйләшеп утырырлык бер кем дә булмаган икән.) Миңа карап шулай сүз башлады:

– Син әйткәнгә ышанмый идем, инде үз күзем белән күрдем, бәла икән сезнең бу Питереңезнең һавасы.Әле мин Уфада булдым, анда бөтенләй җәй инде, коры күлмәк өстеннән каеш буам да өстеннән җиңел бер нәрсәбелән кымыз эчәргә бара идем, ютәл дә юк, авыру да...

Авыруга килгәч тә, Тукай сүзне икенчегә борды.

– Хатын-кыз җәмәгате болай да бәла...  Әмма курсистка булса тагын да бәла инде. Зыялы дип аңардан тартынып, әллә нинди приличие (әдәп)ләр саклап торырга кирәк.

*Билхасса – исемләп, төбәп, аерым алып.*
*Вөҗүд – җан иясе, җисем, бер тән.*
*Бәлиясе – бәласе.*

Тукай гомер буенча хатын-кызга ят булып калды. Хосусан кибар яки зыялы таифәдән булса кача иде. Башта бу ялгыз «шәкертлек авыруы» гына иде шикелле. Соңыннан качуында да шуның корымы бар иде. Ләкин анда, әдәби тәгъбир белән матурлап әйткәндә, «Ибсен авыруы» * да юк түгел иде...

Ул көн безнең өскә тагын берничә кеше студентлар килеп, ахырдан мосахәбә бик «рәсми» булып китте. Ка зандагыча җәелеп, теләгәнчә вә теләсә нәрсә хакында сөйләп утырырга тугры килмәде. Сүз арасында Тукай үзенең бу хәлгә төшүеннән (үз тәгъбиренчә «ялган поза» алырга мәҗбүр булуыннан) шикаять кыйлып та алды.

Икенче көн Тукайны «Нур» газетасының мөхәррире Сафа ахунд Баязитов чакырган иде. Анда Тукай үзенең Петербургка килүеннән бик нык зарланды. Бу зарлануның башлыча сәбәбе: Петербург һавасының юешлеге вә бер дә туктамый бер хәлдән икенче хәлгә күчеп торуы иде. Хосусан аның Петербургка килгән көннәре әллә нинди күңелсез суык һәм юеш булды. Фәкать Тукайның наразыйлыгына мәүҗиб булган нәрсә бу гына да түгел, башкача да бик күп сәбәпләр бар иде. Иң кызыклары шулар:

1) Муса әфәнде ят кеше... өстенә фәүкыльгадә тәкәллефле, – Тукайның үз тәгъбиренчә – төче телле. Төче теллелекне ул үзе шулай тәфсир кыйла: ул менә – Муса әфәнде була инде – юк кына нәрсәне тәкәллефләндереп зурайта, «затегалиләре**, бәндәләре» ди... Әллә нәрсә вә әллә нәрсәләр катыштыра да ике арага пәрдә сала да куя. Шуның өчен никадәр якын булырга теләсәң дә, аның белән рәхәтләнеп, тәкәллефсез сөйләшеп булмый. Ул «затегалиләре» ди бит инде. Аңа каршы син ни дип әйтергә кирәк?..

** Ибсен Генрих – бөтен дөньяга мәшһүр норвег драматургы.*
*Ул да шулай хатыннар мәҗлесендә булуны яратмавы белән мәгъруф. (Автор искәрмәсе.)*
*** Олы, хөрмәтле шәхес мәгънәсендә.*
*Мосахәбә – сөйләшеп утыру.*
*Наразыйлыгына мәүҗиб – ризасызлыгына сәбәп.*
*Фәукыльгадә тәкәллеф – артык дәрәҗәдә төче телләнеп хөрмәт* күрсәтү.

2) Анда Муса әфәнденең җәмәгате бар... Ул гына җитмәсә, аның кардәшләре вә тагын берничә курсисткалар да килә. Өстенә алар тагын һәрвакыт юл өстенә утыралар. Исәнләшсәң, сөйләшеп торырга кирәк, минем өчен тукталып исәнләшеп торуы үзе бер бәла...

Исәнләшмәсәң – килешми.

3) Вообще ул мохит миңа кул түгел... Кичә анда бер байлары * Килгән. Соңыннан миңа аны Петербург мөселманнары арасында бик зур вә бик могтәбәр бер кеше, диделәр. Ишеткәнем дә бар иде... Шулай да күрешергә килгән. Муса әфәнде чакырган булырга тиеш...

Я инде!.. ул миңа ник кирәк?.. Аның миңа ни мөнәсәбәте бар?.. Ул бит әле үзе генә булса ярар иде. Янында Төркиядә укып кайткан бер угылын да алып килгән. Ансы тагын: «Безем госманлы төрекләре, әфәндем...» дип эчне пошыра. Төрек әдәбиятын, солтанны мактап, солтанның җарияләрен мактап гомерләрен үткәргән төрек шагыйрьләрен мактый. Пушкины, Лермонтовы булган бер мәмләкәттә килешәме инде!.. Килешмәгәндә эше юк, ул һаман үзенекен сөйли. Аңа ни дип әйтергә кирәк! Грубить итә – тупаслана башладым.

– Мактыйсыз да мактыйсыз, я, әйтеңез зинһар: Пушкин яки Лермонтов дип әйтерлек кемнәре бар? – дидем. Аңарга да аптырамады. «Әфәндем, әфәндем?», дип торды-торды да әллә кем вә әллә кемнәрне санарга тотынды. Санаганда да кемнәрне саный!.. Намикъ Кәмал, Габделхак Хәмид, Мәхмүд Әкрәм, Әмин бәк–фәләннәр белән калса ярар иде. Әллә кем вә әллә кем«бәк»ләрне санап китте...

Түзә алмадым – башымны «җүләр»гә салып шаярта башладым. Бер сөйләп бетә, мин аңлап җитмәгән булып яңадан кайтарып сорыйм, ул тагын башлый. Тагын вә тагын шулай. Бик кызык бит... Ул шул арада бик чынлап әллә никадәр нәрсәләр сөйләп алды.

Башта атасы – пәдәр мөхтәрәмнәре – буңа бик куанып утыра иде. Соңыннан аның да эче поша башлады. Минем шаяртканны да сизде шикелле: «Муса әфәнде кайтмады!» – ди башлады.

– Ул бер профессорның лекциясен тыңларга гынакиткән иде. Бер-ике сәгатьтән артык тормас, – дидем.

** Петербургның күренекле купецларыннан берсе Галим Максудов.*

Ул бу сүзнең дә усаллык белән әйтелгәнен аңлады шикелле.

– Килергә чыккан вакытта сул аяк белән чытъшган, ахрысы, – диде. Мин тагын да җавапсыз калдырмадым:

– Бисмилласыз чыккансыз булырга кирәк; бисмиллаңызны да онытмаска кирәк иде, – дидем. Моңа тагын да ачуы килде. Шуннан соң инде үзем дә тәмам котылдым. Бүген Тукай, Сафа ахундтан минем квартирыма (комнатка) килеп, миндә кунып калды.

II

Миңа килгәнче, Тукай Петербургта дүрт кич кунган иде. Миндә бишенче кичен кунды. Бердән, Петербург һавасының начарлыгы, икенчедән, гел үзенең мәсләгенә муафыйк

булмаган бер кыйсем Тукайның үз тәгъбирен-чә – «ялган рәсмият» белән генә дөньяда тора торган халык арасына төшеп, «җан сыкынтысы» пәйда булуы аркасында ансыз да киң холыклы түгел Тукайның холкы тагын тарайган, кәефе тәмам бозылган иде. Электә күргән, белгән, бервакыт бик якын иптәш булган, шунлыктан һич тартынып, тәкәллефләнеп торырга хаҗәт төшми торган бер кешегә килгәч, Тукай бераз сулыш алырлык хәлгә килгәнен сөйләде.

– Петербурга килгәнемә биш көн булды, «агай-эне» дән һич кемне күргәнем юк, һәркемнән элек күрермен дип килгән сине сорасам – белмиләр... Башта чынлап та белмиләрме икәнни дип гаҗәпләнгән идем. Соңыннан сынап торсам, мондагы халыкның ике партия булган булып йөргәнлекләре аңлашылды. Муса, Лотфи (әфәнде)ләр бер партия булып, Сафа мәхдүм әтбагасы белән үзенә бер партия икән дә, гүя син шул партияләрдән беренең «чынлап» хезмәт итеп йөри торган бер кешесе икәнсең... Партия дошманы булган буласың инде!.. Мине дә шул партияләрдән беренә кертеп батырмакчы булганнар. Башта мин «Нур» идарәсендә булган һәм дә үзләренә катышып йөргән бер кешене белмәүләренә бик гаҗәпләнгән идем.

*Мәсләк – тоткан юл, дөньяга караш.*
*Кыйсем – өлеш, кисәк*
*Әтбагасы – иярченнәре.*

Дүрт-биш көн һич кайда чыкмый, белгәй-күргәннән һичбер кешесез мәхбүс ятканнан соң, кичә Петербург курсларыннан берендә укый торган Шәрифел-Әхмәди * дигән бер әфәнде килде. Бераз сөйләшкәннән соң, Сафа мәхдүмнең визит карточкасыны биреп, иртәгесе квн өйләдән соң сәгать бергә Сафа әфәнденең үз өенә чакырганлыгын сөйләде. Муса әфәнде миңа һич хәбәр итмәстән, аңа бик катгый рәд җавабы бирде. Юк кына нәрсә өчен бик кызып:

– Булмас, иртәгә аның вакыты юк, чакырылган йиремез бар, – диде.

Кунак дигән булып, мещаннарча минем өстемнән болай хуҗалык йөртелүенә намусым килеп китте. Кем икәнен ачык белмәсәм дә, ул чакырган кешенең нинди булса бер извозчик я халатчы, ягъни миңа һич мөнәсәбәте булмаган бер кеше икәнлеге белән хөкем кыйлдым. Җавапның бирелү рәвешендә бер дә чакырылмаган булып та «вакыт юк»ка сылтау булуы бик ихтимал иде. һәрхәлдә бу эш минем ихтыярымнан башка булырга тиеш түгел дидем дә, халык арасында булган гадәткә, йорт хуҗам Муса әфәнденең теләгенә хилаф уларак, мин үземнең Сафа әфәндегә барырга теләгәнлегемне белдердем, визит карточкасыны китергән кешегә шулай вәгъдә бирдем,– диде.

Шул арада Тукай үзенең Петербургка килү тарихын да бик баблап, бик тәфсыйлләп сөйләде. Муса әфәнденең чакырып язган хатын күрсәтеп, үзенең ни өчен чакырылганлыгын бер дә аңлый алмаганлыгын белдерде. Хат Муса әфәнденең каләме белән язылган һәм дә Тукайны чакырыр өчен махсус язылган. Муса әфәнде Тукайны бер үзе исеменнән генә чакырмый, берничә кеше кушылып, Тукай шулар исеменнән чакырылган. Хатта Тукайга махсус аерым бер номер алыначагы вә анда Тукай өчен – теләсә – һәртөрле эчемлекләр дә булачагы тәэмин ителгән. Петербург өчен бер кат кием вәгъдә ителгән. Килер өчен акча җибәрелеп, кайтыр өчен дә билет алыначагы зикер ителгән иде. Моңа кадәр беркем тарафыннан да мондый кызык бер илтифат күргәне булмаганлыктан (үзе шулай ди), Тукай бу хатны алган вакытта да нинди дә булса бер максат белән язылган булырга кирәк дип уйлаган икән.

** Шәриф Әхмәтҗаненә (Манатов)*
*Мәхбүс – тоткын.*
*Катгый рәд җавап – кискен каршы җавап.*
*Хилаф – каршы.*

Бүген һәм шуны сөйләде. Моңа Петербургта «Сүз» я «Хәб^р» исемендә бер газета чыгарылырга уйланганлыгын кушылып, төрле ихтималлар йөртелде. Петербургта чыгарылуы уйланган бу газетада Тукайның баш мөхйррир итеп куелу фикере дә сөйләнде. Шуннан соң Тукай үзенең ни өчен чакырылганлыгы хакында катгый бер карар ясап, күңелен тындырды. Юкса тора да:

– Я инде, минем Муса (әфәнде) гә ни кирәгем булырга мөмкин?.. Син теләсәң нәрсә әйт, әмма мин үземне Муса (әфәнде) гә бик үк тансык кеше булырмын дипбер дә ышана алмыймын, – ди иде.

Хатта Тукай кыш көне – югарыда исеме зикер ителгән газета чыгарылуы уйланган вакытка чакырылган. Ләкин ул вакыт Тукай килмәгән, хәзер – яз килгән, хәзер исә газета чыгарылу ихтималы бөтенләй беткән иде. Шунлыктан Тукай шундый бер карар чыгарды:

–Хәзер шөбһә калмады, вакыйга шулай булырга кирәк, мин ул вакыт нинди булса бер кирәк өчен чакырылганмын, хәзер инде ул кирәк беткән, шуның өченминем ул миңа һич мөнәсәбәтләре булмаган бер халыкта кунак булган булып ятуым килешми, өстенә авырулыгым да юк түгел, ул да, әлхәмделилла, бар; шулай булгач, мин инде ул кешеләргә коры йөк булып ятмый, китәргә тиешлемен. Янымда илле сум акчам бар. Бүген синдә куныйм да, иртәгә, аллага тапшырып, Уфага юнәлим. Юкса монда көннән-көн рәхәтсезлегем генә арта, – диде.

III

Бердән, өч ел торылган бер җир... Петербург минем өчен хакы химая кылынырга тиешле бер ватан булган, шуның өчен Тукайның бу рәвеш, гомерендә бер килеп тә, аннан риза булмый китүе күңелгә бик уңгайсыз. Икенчедән, бик якында мәңгегә аерылу ихтималы булган Тукайның үзе дә бик күп нәрсәләрне күңелгә китерә. Моңа кадәр вөҗүде һич лаекынча тәкъдир ителмәгән бу яшь талантның хәзер инде күз алдында торуы да аерым ис тугдыра башлаган.

*Химая кылынырга – якланырга.*

Чын мәгънәсе белән нади-релвөкүд бер кеше булганлыгы галәбе кыйла торган булгаҗ Шуның өчен тагын да аны болай гына җибәрәсе килми. Тотасы, торгызасы, пайтәхетнең яхшы-яман, кызык-кызык җирләрен күрсәтеп, бераз күңелен күтәреп җибёрәсе килә. Шуның белән бергә, чынлабрак уйланыргаутиешле булган икенче бер нәрсә дә бар. Ул бит кеше кунагы, аның аннан чыгуы да әллә нинди күңелсез сүитәфәһһемнәрне мәүҗиб булырга мөмкин. Менә туларны уйлаганнан соң, мин Тукайга шулай дидем:

– Тукай, менә нәрсә: син бүген Муса әфәндегә кайт, мин извозчик белән илтим... Син бүген мотлак анда кунарга тиешлесең. Син ни дисәң, аны әйт, әмма асылда син хуҗаңның хуҗалык хакын үтәргә тиешсең, гадәт бу... этика да шуны тели, бүген кайт, иртәгә син китәргә җыенган вакытта без барып сине үземезгә кунакка чакырырмыз, минем үземнең бер атна кунак итәрлек хәлем бар. Сафа әфәнде дә: «Мөмкин булып калдырып булса, берәр ун көн алып кунак итәргә кирәк», дигән иде, – дидем.

Боңа каршы Тукайның әйткәне шул булды:

– Моңа кадәр дөньяның гадәт, этика дигән нәрсәләрен танымаганны, хәзер инде, Петербурга килдем дип, мин сезнең ул этика, гадәт дигән нәрсәләреңезне җиренә җиткереп тора алмыймын. Гаеп итә икән – итсен. Андый гаеп ителүләргә минем исем китми, һәр нәрсәдән элек ул (Муса әфәнде) минем мәдрәсәдән шәкертенең атасына чакырылган бер кунак-хәлфә генә түгел икән легемне белергә тиеш... Мин үземнең кем икәнемне бик яхшы беләмен... Мин читлек кошы түгел, мин – вольная птица, кайда теләсәм, шунда кунам...

Шул җиргә җиткәндә, студент Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров килеп, сүз бөтенләй икенче «тон», икенче рухка кереп китте. Тукай Петербургка килгәч, Шакир әфәнде белән күрешмәгән икән, күрешеп, хәл-әхвәл сораша башладылар. Шакир әфәнденең бер нәрсәдән хәбәрсез, шат-шалтырап тора торган садә, кайгысыз йөзе Тукайга бик ошап китте. Чәй эчә идек.

*Надирелвөҗүд – барлыгы, яшәве бик сирәк була торган.*
*Галәбә кыйла – җиңә, күз алдына килә.*
*Сүитәфәһһемнәрне мәүҗиб булырга – начар уйлар уйлатырга сәбәпче булырга.*
*Мотлак – һичшиксез.*

Эчә торгач, самоварда су бетте, һич килмәгән ашыйсыны китереп, ашар өчен күңеллерәк бер җиргә чыкмакчы булдык. Ул арада Кәрим Сәгыйть әфәнде, тагын бер-ике кеше килеп, алар да һәркаюысы үзләренчә мәҗлескә бер рәнк – оттенок бирделәр. Сүз иярә сүз чыкты, бая сөйләгән күңелсез сүзләр бар да онытылдылар. Эч пошырып, бер мәсьәләне озак сузып сөйләүләр бетте, һәрнәрсә мөхакәмәсез кабул ителә башлады. Бөтен бүлмәне шатлык, яшьлек, тәкәллефсез иптәшлек рухы күтәрде. Тукайны бик шәп рестораннардан беренә алып барып «ужин» иттерергә булдык. Ул тагын да рухны күтәрде. Без барырга уйлаган ресторан өчен катыргылы ак яка мотлак лазем булып, Тукайда ул юк иде. Якалар эзли башладык, һичбер яка яратып булмады. Нинди генә яка кидерсәң дә, зур була. Кечкенә ябык атка зур камыт кидергән кебек, килешми иде. Ниһаять, бер манжет (җиң очы)ны урталай ярып, пәке очы белән тишекләр ясап, Тукайның муенын ак яка эченә алдык. Тукай мондый нәрсәне һич яратмый торган иде. Монда да бераз тартышып карады. Ай-ваена куймадык. «Петербург хөрмәтенә» дигән булып риза булды. Өс-башы зарарсыз иде. Дәрвишрәк булса да, сюртугы бар, Петербургка килер өчен инглизләрчә тегелгән яхшы пальто алган, башында немец эшләпәсе, кулына таяк тоткан. (Тукай элек-электән дә таяксыз йөрми торган иде. Таякны ул иптәшлек өчен ала торган иде.) Халык кузгалып, һәркаюысы бик шәп бер ресторанга алып барамыз, ди башлагач курыкты:

Андый җирдә тагын әллә нинди приличие (әдәп)ләр саклап торырга кирәк булыр бит, простойрак булса нишли? Миңа ничек тә ярый, – ди башлады. Гомерендә бер Петербургка килгән кешене ничек итеп гади бер җиргә алып барасың?.. Садәрәк булса да, беренче класс ресторannардан берено алып бардык. Ишектән кергән вакытта Тукай тагын бер туктап:

– Монда хатын-кыз җәмәгате бик күп түгелме инде? – дип кире чигенә башлады. «Юк!» дидек. Булса да, хатын-кыз Таифәсеннән ераграк утырырга вәгъдә бирдек. Ул шул арада үзенең, кайдадыр бер җирдә шундый зур ресторannардан берено барып та, бөтен өстәл әтрафын әллә нинди кибарлар белән генә чуала торган кызлар коршап алганын сөйләде. Үзенең һич андый халык белән «килешә» алмаганлыгын бәян итеп:

– Кунак итеп алып барган хуҗалар шул бәдбәхет хатын-кыз белән әварә булып киттеләр дә, мин бичара бер үзем ялгыз тордым да калдым, – диде. Без, безнең белән андый эш булмаячагын бик нык тәэмин итеп, бөек пайтәхет ресторанының биек баскычларыннан Тукайны култыклап югары атладык...

*Мөхакдмәсез – бәхәссез, тартышсыз.*

IV

Бүген Тукай миндә кунды. Квартир хуҗамыз күнсә, Тукайга шул көн генә бушаган икенче бер комнатны алып, Тукайны шунда калдырырга уйлаган идек. Тукайның төн буе карых-карых йөткереп чыгуы ансыз да җаны уч төбендә торган Петербург марҗасын куркытты. Без комнатны алырга сорамастан элек, мине аш бүлмәсенә чакырып, кунагымның туберкулез түгелме икәнлеге хакында сораша башлады. Бу вакыт Тукай чынлап та шикләнмәслек түгел иде. Минут саен әллә ничә мәртәбә карых-карых йөткерә, вакыты-вакыты белән тотлыгып, әллә никадәр газапланып тора иде. Шунлыктан башка җирдә дә арурак бүлмә я номер табуы кыен булыр төсле күренә башлады. Шуның өчен иң элек Тукайның йөткерүен йомшатырга бер чара эзли башладык. Ул үзе моңа кадәр шуның өчен дә бер чара кирәксенмәгән иде. Бер стакан сөт кайнаттырып, ярты бутылка сельтерский катыштырып эчердек. Аның артыннан «гуй-ю» капсульләре йоттыра башладык.

– Мин үзем дә бервакыт шулай йөткерә башлаган идем, «гуй-ю» капсульләрене йоткач, кул белән сыйпап алган кебек булдым – бер нәрсә калмады, – дигәч, Тукай бу капсульләрнең шифасына бик нык бер канәгать хасил кыйлды вә чынлап, һич вакытын качырмастан, шул капсульләрне йота башлады. Безгә шулай тоелдымы, әллә чынлап та файдасы тидеме, кайнаган сөт белән сельтерский эчереп, мәзкүр капсульләрне йоттыра башлагач, Тукайның тотлыгып торып газап чигүләре чынлап та кимегән кебек булды. Тукай хәтта:

– Бу «бүре балаларын»2 кичә йоткан булсак, синең хозяйка әллә калдырган да булыр иде, хәерле булсын инде, – дип, кичә йоткан булса, йөткерү бетеп, авыру икәнчелеге беленмәс төсле итеп куйды. Яшерергә мөмкин түгел, квартир хуҗалары артык назикләр, Тукайның анда калу ихтималы юк иде. Тукайга миннән ерак түгел, һәрвакыт кереп торырлык якын бер җирдән номер алырга булдык. Тукай калырга булды.

Көндезге ашка Сафа әфәнде Баязитов чакырган иде. Анда мин, Тукайны Муса әфәндедән алып, бер атна үземездә кунак итәргә уйлаганлыгымны белдердем. Моңа каршы Сафа әфәнде: «Муса әфәндедән уңайсыз булмаса, мин дә кунак итәр идем, әгәр дә Тукай мин катышмаган вакытта да Муса әфәнделәрдән чыга торган булса, бу бер атнаны ун көн итеп мин үзем кунак итәм», – диде. Мин Тукайның Муса әфәнделәрдән болай да чыгачагын сөйләдем. Без кунак итмәгән вакытта, Тукайның Петербургтан китәчәген һәм дә бик наразы булып китәчәген белдердем.

Тукайның хәлен уйласалар, Муса әфәнделәр үзләре дә бу эшкә рәнҗемәскә тиеш икәнчелекләрен сөйләдем. Шулай итеп Тукай калырга булды. Сафа әфәнде номер өчен тәүлегенә 1 сум 50 тиеннән ун көнгә 15 сум акча чыгарып бирде. Бер сум 50 тиенгә күңел яхшы канәгать кыйлып торырлык яхшы номер табылмаса, 2 сум, 2 сум 50 тиенгә кадәр алырга яраганын белдерде. Ашау-эчү өчен һәр көн Мойкага, Сафа әфәндененң Мойкада мәсҗед хозурындагы квартирына йөрергә булдык. Тукайны бик мәшһүр бер докторга алып барырга көн тәгаен ителде. Шул ук көн Тукай белән извозчикка утырып, берничә номер

белештек. Ахырында Петербургның иң урта бер җире – Невский проспекттан өч йорт аша «Казанский бишенче номер» исемле мебельле ком-натлардан берен алдык. Тукайны номерга кертеп күрсәтеп, бик яратып чыкканнан соң, тугры Муса әфәндегә барып, шул ук извозчик белән аннан Тукайның нәрсәләрене алып килдек. Без барганда Муса әфәнде өйдә юк иде. Тукай үзенең алган номерының адресын язып:

«Хөрмәтеңезгә рәхмәт, мин менә шул номерларга күчеп, бераз үз башыма ялгыз торып карарга уйладым», – дип, Муса әфәндегә записка калдырып китте.

*Назик – нәзберек.*
*Нарази булып – ризасызлык белән.*

Тукайның чын Петербург хәяты шул көннән башланадыр.

Аерым номерга чыккач, Тукай тәмам иркен бер сулыш алганлыгын сөйләде. Бу вакытны сөйләгән сүзләреннән хәтердә калганы шул булды:

– Тагын үземнең мөкатдәс ялгызлыгыма кайттым...

Мин теләсә нәрсә әйтергә ярый торган иптәше; Сафа әфәнде катышмый, номер акчасын вә бөтен мәсарифен түләп, бөтенләй үз кунагымыз итсәк тә, шуннан злек кенә анда кунак булам дип күңелсез бер мәхбүсияткә дучар булудан зарланганлыкны күргәч, без аны – Тукай әйтмешли – үз ишәгемез итеп кенә калдырырга теләмәдек. Алла тарафыннан гомум халыкка бирелгән кадерле бер гатыя икән, без аны «милек» кыйлып халык кулыннан ник тартып алыйк, дидек.

Хәл-әхвәл, бәгъзе анда булган мөнәсәбәтләр дә шуны моктәза иде... «Йорт» хуҗасы – Тукай үзе. Белеш, таныш һәркаюысы килә, теләгәнчә утыра, сөйләшә... Чыккан-кергән вакытта юл өстендә уңгайсызлап утыра торган курсисткалар, хатын-кыз җәмәгате дә юк... Кыскасы, Тукайга номерга чыккач, мөбтәла булдыгы авырудан башка, «җан сыкынтысы» бирә торган бер нәрсә дә калмады. Өши-калтырый (бизгәк тота) башласа, хәзер «аспирин» (порошок) йота, иртә-кич вә көн урталарында «гуй-ю» капсульләре каба, бик көчләсәң, сельтерский белән кушып кайнар сөт тә эчә иде. Эчүе бик авыр булганга, бу соңгысын бик кыйналып кына тыңлый иде.

Петербургка килгәндә Тукай нормальный – сау кешелектән чыккан, бөтен вөҗүде гайре табигый бер рәвештә генә яши башлаган иде. Ашап-эчеп җылыну, пичләр ягып җылы табу дигән нәрсәләр беткәнгә якын...

*Мәсарифен – расходларын, чыгымнарын.*
*Мәхбүсияткә – тоткынлыкка.*
*Гатыя – бүләк.*
*Шуны моктәза иде – шуны таләп итә иде.*
*Мөбтәла – дучар.*

Ит юк, кан беткән дип әйтерлек дәрәҗәдә ябыккан, хәлсез коры бер сөяк кенә калган иде. Бердәнбер тәхәллеф-сез җылыта торган дәва булса, ул да аспирин. Аны да кеше шикелле «доза» – могайян бер микъдар белән эчеп кенә җылынмый. Чәй кашыгы тутырып эчәргә кирәк, шуннан соң гына җылына.

Казанда чакта Тукайдан мин дөньядан туеп сөйләнгән сүзләрне күп ишеткәнем бар иде. Ул вакыт уйный-көлә әйтелгән ул сүзләргә һич әһәмият бирелми торган иде. Бүгенге мосахабәдән соң мин Тукайның һәрбер сүзенә мәгънә бирә башладым. Моннан соң бәгъзе шигырьләрендә булган нөктәләр дә ачылды... Дөньяның байтак суык-җылысын күргән миңа аның соңгы сүзләре бик авыр бер тәэсир калдырды. Ул тәмам шулай диде:

– И мулла Кәбир, мулла Кәбир! Яңадан өч ел дөньяда торсам үкенмәс идем!..

Бу сүз Тукайның соңгы вакытлары өчен даими бер сүз булдымы, әллә иттифакый– настроение – кәефе шулай тугры килеп кенә әйтелдеме. Моннан соң мин аның авызыннан дөньяда торырга шундый зур бер теләк саклап йөргәнлеген ишетмәдем.

VI

Тукай номерга чыккач, берничә көн Муса әфәнделәр тарафыннан һич катнашучы булмады. Моңа Тукай вөҗданән бераз рәхәтсезләнде шикелле. Ул хакта сүз чыкты исә:

– Килмәгәннәре яхшы, – ди иде. Килмәүләренең ни өчен яхшы булганлыгын мин сорамадым, ул әйтмәде. Шунлыктан ул килмәүнең ни өчен яхшы булганлыгы шул көнгә кадәр мәтви калды. Хәзер дә уйга килә: «ник хшы?» дип сорасаң, нәрсә әйткән булыр иде икән?..

Номерга чыккач, Сафа әфәнде башта берничә көн аш хәзерләтеп чакырды. Берме-икеме баргач, Тукай ун-гайсызлана башлады. Элек «барырбыз» дип тора-тора да, барыр вакыт җиткәчтән бармау ягын тарта:

– Невский аша чыгарга кирәк, я таптарлар, мөмкин булса, шушы тирәдә бер җирдә ашарга кирәк, – ди иде.

*Тәкәллефсез – каршылыксыз.*

Ул чынлап та Невский аркылы чыгарга курка иде. Андагы «выж да выж» һәр тарафка үтеп торган гайре мо-танаһи (хисапсыз) автомобильләр, трамвайлар аңа бик куркыныч тоела, извозчик белән барган җирдән дә таптап китәр төсле күренә иде шикелле.

Бервакыт тәрәзә каршысында садә генә (садә булса да пөхтә) бер ресторан күреп: «Шунда ашатмыйлармы икән?» – диде. Ашата торган һәм дә яхшы, пөхтә ашата торган булгач, һәр көн ике мәртәбә шунда кереп ашый торган булдык. Аш алдыннан кан җылытыр өчен беренче итле ике блюдага бирәрдән ике рюмка портвейн эчә, шуның белән бик рәхәтләнеп сөйләшеп аш ашый идек. Аннан соң шундук чәй әйтеп чәй эчәргә тотынабыз. Шулай итеп байтак вакыт уза торган иде. Ахырдан хәтта иптәшләр дә, Тукай өйдә булмаса, шунда кереп таба торган булдылар. Кеше килгәч, өйдә утырырга да ярый дип, өйгә кайта идек. Анда тагын самовар куйдырып, бишәр-алтышар кеше җыйналып чәй эчәбез, шулай итеп кич була иде.

Бер көн Сафа әфәнде Тукайны гаиләсе тора торган үз өенә (алтынчы Рождественскийга) чакырды. Алдан хәбәр ителеп, пайтәхетчә шактый тәкәллеф белән төрле блюдалардан аш хәзерләнгән, өстәлгә кунак саен бер данә бик матур тулы, янып торган саф, хуш исле аллы-гөлле (роза) чәчәге куелган иде.

Аш алдыннан кунак залына кертеп, Сафа әфәнде граммофонда берничә Пушкин вә берничә Лермонтов шигырьләре куеп тыңлатты. Башта Лермонтовның «Демон» кыйтгаларын куен караган идек, Тукайның бер дә ләззәтләнә алмаганлыгын күргәч, «Евгений Онегин» (Пушкин әсәре) нән мәшһүр арияләрне куйдык.

Казанда икән, Тукай белән бер мәртәбә шәһәр театрына барганымыз исемдә иде. Ул вакыт Гогольнең «Ревизор»ы («Мөфәттиш») куелган һәм дә яхшы, муаффәкыятьле уйналган кебек булган иде. Шулай да Тукай (үз сүземе, берәр тәнкыйтьче сүзен күрепме), уенның беренче пәрдәсе уйналгач та:

– Гоголь үз каһарманнарының битләрен үзе бик яман былчырак белән буйый да үзе шулардай көлә, – дигән иде. Байтак җитди рус тәнкыйтьчеләре тарафыннан «Ревизор»ның рус хакыйкатенә муафыйк танылганын укып күңелемә утырткан булсам да, Тукайның әсассыз, юкка гына сүз сөйләргә яратмаганлыгын хәтеремә

китереп, каршы бер сүз дә әйтмәгән идем. Бүген Сафа әфәндедә «Евгений Онегин»нан граммофонга алынган бөтен кыйтгаларын куеп чыккач, Тукайның үз гомерендә бер мәртәбә опера күрмәгәнлеген ишетергә тугры килде. Тукай иттифакый тугры килеп (андый эшләргә ул һәрвакыт иттифакый гына тугры килеп бара иде), рус театр сәхнәсендә драма күргән булса да, опера күргәне юк икән. «Шагыйрь булып, шул көнгә кадәр бер опера уйналганын да күрмәдеңме?» – дип гаҗәпләнә башлагач, җиңел генә:

– Көчләп алып баручы булмады, болай барылмаган, күрәсең, – диде.

– Алай булса, Петербургка килүеңне опера белән ознаменовать итәргә (ягъни опера күрү белән күңелдә калдырырга) кирәк дип, Тукайга бер опера тыңлатырга булдык. Мариинский театрга * билет алу читен иде. Телефон белән «Народный дом»нан билет сораштык. Өч көннән «Евгений Онегин» куелачак иде. Шул көнгә икенче рәттән билетлар китерергә булдылар. (Беренче рәткә, бигрәк кеше күз алды була дип, Тукай күнмәде.)

Билетлар килде, көн җитте, ләкин Тукай һаман да опера күрә алмады. Бик каты яңгыр явып, суытып, шул суык һәм юешлек тәэсире илә Тукай үзен-үзе белмәслек дәрәҗәдә бизгәккә сабышты. Ул көн, күптән ягылудан тукталган пичләрне яктырып, кич белән сәгать 9 дигәндә көчкә Тукайны җылыттык. Шул бизгәкнең тәэсире белән икенче көнне докторга күренергә риза булды. Шакир әфәнде Мөхәммәдьяров университетка барып, үзләренең бик яхшы бер докторларын (университет докторы Польне) китерде. Шулай итеп Тукай гомерендә икенче мәртәбә (яңлыш булмас шаять, дип уйлыйм) докторга күренде. Анда да кеше алдында күренергә теләмәде. Икенче бер бүлмәгә чыгып, шунда күренде. Докторга Тукайның кем икәнлеге алдан бик яхшы төшендерелеп куелган иде. Шунлыктан доктор аны бик зур бер илтифат вә дикъкать белән карады. Асыл авыруын (чахотканың ахыргы дәверләрендә идекен) үзенә әйтмәде Тукайның доктор киткәч әйткән сүзе әле дә хәтеремнән чыкмый. Ул вакыт ул:

– Гомеремдә ике мәртәбә докторга күрендем, беренчесе газраил кебек җанымны алган иде, икенчесе үлгән тәнгә рух өрә торган фәрештә булып чыкты, – диде.

*Хәзерге Киров исемендәге опера һәм балет театры.*
*Иттифакый – очраклы.*

Вакыйгән, доктор бик яхшы тугры килде. Кызганып һәм дә Тукайның шул арада сөйләгән бәгъзе балалар кебек беркатлы сүзләрене яратып, килеп йөргән өчен мәшәкать хакы да алмады. Доктор Тукайның үзенә:

– Зәгыйфьлектән башка авыруың юк... Тазарсаң(?) бетәр... Фәкать моның өчен яхшырак санаторийлардан беренә барып, бик яхшы тәрбияләнергә кирәк, – дигән икән. Тукай:

– Кымызга барсам, булмасмы? – дип бик исрар кыйлгач: «Кымыздан яхшы файдаланырга мөмкин.тик бик пөхтә җир булырга кирәк»,– диде, ди. Озаткан вакытта Шакир әфәндегә (хәрфиян) шулай дигән:

– Туберкулезның соңгы дәвере, бер үпкәсе (кайсы як икәне хәтердә калмаган) череп беткән. Икенче үпкәсенең дә яртысы гына калган. Тын ала торган әгъзаларның дүрттән бере белән генә тын алып тора.

Бу хәл ул вакыт доктордан башка да беленергә тиеш иде инде. Тик Тукайның электән гәүдәгә бик зәгыйфь булып, өстенә хәзер дә, кәефе килгәндә, сәламәт кешеләрдән артык гакыллы вә мөтайбәле сүзләр сөйләп торганлыгын күреп, авыруның ул дәрәҗәгә килгәне уйланып җитми иде. Шакир әфәнде докторны озатып, хакыйкать хәл мәгълүм булгач, шунда булган иптәшләр үзара җыелышып кайгыртырга тотындык. Швейцария кебек берәр җирдә яхшы санаторийлардан беренә җибәреп дәвалаган вакытта, үпкәсен катырып, өч-дүрт ел гомерен озайтырга мөмкин икәнчелеге доктор тарафыннан сөйләнгән иде. Байтак сөйләшкәннән соң, шул хакта бер чара табарга да мөмкин кебек булган иде. Иптәшләрдән кайсы бер йөз, кайсы ике йөз акча (кешедән әлбәттә) табышып, дүрт-биш йөз сум акча табылырга булган вә шул акчага берәр җәй Швейцариядә Тукайны тәрбия кыйлып чыгарырга уйланган иде. Аннан башка да андый эшләргә бик тиз күндереп булмый торган Тукайга доктор тарафыннан бирелгән тәскинат җитә калды.

*Исрар кыйлгач – үз фикерендә каты торгач.*
*Хәрфиян – сүзгә сүз (хәрефкә хәреф).*
*Мөтайбәле – матур, хуш исле, ягымлы.*
*Тәскинат – тынычландыру.*

Бер тарафтан Тукайны «сәламәтлек» белән куандырсак, икенче яктан авырудан котылдыру тарафының юлларын будык, һичнәрсәгә карамастан, доктор сүзенә ышанып, Тукай үзенең сәламәтлеген дәгъва кый-ла башлады. Авыру юк, тазарыр өчен Троицк ягына барып кымыз эчәргә генә хаҗәт булганлыгын исбат кыйлырга тотынды. Бөтен өметләр бетте. Үз мөсаһәләмез белән үземез Тукайны пие – былчырак казакъ сахрасына атарга мәхкүм булдык. Тукай да:

– Күрерсез, көзгә адәм танымас дәрәҗәдә шишман булып кайтмасам...– дигән булып Уфа аша Троицкига кымыз эчәргә китәргә булды.

VII

Петербургка килгән вакытта аның янында икеме-өчме бер җирдә дә басылмаган яңа шигырьләре бар иде. Ул шигырьләр Уфада салынган көе бик иске бер пиджагының кесәсендә яталар иде. Докторга күренгән кичтә ул шул шигырьләрен алып миңа укыды. Тукай доктордан никадәр мәмнүн булса, номерда калып докторга күренергә сәбәп булган кешеләрдән дә шулкадәр мәмнүн иде. Билхасса, «Нур» мөхәррире Сафа әфәнденең илтифатына каршы зур бер миннәтдарлык белдерә иде. Шөкране нигъмәт йөзеннән «Нур»га шул шигырьләрдән, берене дәреҗ иттерергә бирмәкче булды. Моның өчен иң мөнасиб булганы «Дин вә гавам» шигырьләре иде. (Хәтеремдә шулай калган.) Ләкин соңыннан аның да «Нур» мәсләгенә муафыйк булып җитмәгәнлеге аңлашылды. (Бу

шигырьдә Тукай хәзерге дин башында торучыларны «каргалар» дип атый. «Нур» исә мелла вә мөәзиннәр «органы» булганлыктан, дин башында торучыларга ул тарызда тел тидерергә разый түгел.) Шулар яныньдук игътибарсыз төрелеп ташланган илле сум акчасын да алып, бер 25, ике ун, бер 5 сумга ваклатып куйды.

*Мөсаһдлә– йомшаклык күрсәтү, җиңелгә санау.*
*Мәмнүн – канәгать, риза.*
*Билхасса – бигрәк тә, төбәп.*
*Миннәтдарлык – яхшылыкны тану.*
*Шөкране нигъмәт – нигъмәткә каршы рәхмәт белдерү.*
*Тарызда – рәвештә, сурәттә.*

– Алай-болай капылт кирәк булса, тоташ илле сумны берьюлы ваклау кыен булыр, – дигәне хәтеремдә калган.

Номерда тора башлавына дүрт-биш көн үткән булса да, Муса әфәнделәр тарафыннан килгән-киткән кеше юк иде. Үпкәләделәрме (ни өчен?), юкса әһәмият бирәселәре килмәдеме–хәл-әхвәл сорашкан кеше дә булмады. Докторга күренгәннән соң, яшьләр вә Петербург гали мәктәпләрендә укый торган студент вә курсистлар катышып, Тукайны без көннән-көн кутәрдек. (Самими бер кадер күрсәтә идек инде, аның өстенә «махсус» та күтәрә идек.) Бу вакыт Тукайның Петербургта килгәнен «сизмәгән» кеше аз булгандыр. Муса әфәнделәрдән чыгып, номерда тора башлау вакыйгасы байтак «интрига»лар да ясады. Үзенә күрә бер сенсация (зур вакыйга) булды. Иптәшләре вә, Сафа ахунд кебек, Тукайны ничек тәрбия кыйлса, алай тәрбия кыйлырга көче җитә торган бер кеше тарафыннан һич ярты юлда калмый торган илтифатлар кыйлынып торганлыгын күргәч, Тукай да аркасын бик нык терәп, күңелен тынычландырды. Ул арада читтән кешеләр аша хәбәр җибәреп, Тукайның әллә кем вә әллә кемнәргә «мәдгу» – чакырылмыш булганлыгын белдереп, һич хәл-әхвәл белешмәстән, фәлән вә фәлән вакытка Тукайның хәзер булып торырга тиешлеке хакында Муса әфәнделәр тарафыннан тәнбиһләр ясала башлаган иде. Тукай бу тәнбиһләргә каршы:

–Иң элек, мин Петербургка «пурки» булып ашка йөрергә килмәдем. Икенчедән, мин бервакытта да ул кешеләргә барам дип вәгъдә биргәнем юк, – дип җавап кайтарды.

VIII

Бервакыт Тукай бик озак «Нур» идарәсендә утырды. Идарәгә килгән мәктүп, мәкалә вә газеталар эчендә берничә шигырьләр белән «Йолдыз»да Казан имамнарыннан Садыйк хәзрәт Иманколыйның бер мәкаләсе бар иде. Бу мәкалә Муса әфәнденең «Вакыт»та (1912 нче ел 957 нче номерда) язган «Татар дөньясында ризаләт» дигән мәкаләсенә каршы язылган, Муса әфәнде мәкаләсендә булган бәгъзе сүзләрне җәрех кыйлып, Муса әфәнде тарафыннан кулланган бәгъзе гыйбарәләрнең җөзафлыгын, әдәпкә хилаф булганлыгын күрсәткән иде. Мин – ул вакыт «Нур»да секретарь булуым игътибары илә – Садыйк хәзрәтнең бу мәкаләсен бик гакыллы язылган бер мәкалә итеп тапсам да, Муса әфәнде мәкаләсенә каршы бик сыек дип, кертмәү ягында булганлыгымны белдердем. Сафа әфәнде дә шуңа якын бер фикер бәян итте:

– Без бу мәкаләне бастык исә, шәхси дошманлыкка гына хәмел кыйлалар, – диде. Ул да басмау ягын тәкъвия кыйлды. Тукай бу мәкаләне укып чыкты да:

–Мотлак, басарга  кирәк, тик үз тарафыңыздан нинди булса бер сүз дә арттырырга кирәк, – диде.

*Тәнбиһ – искәртү, белдереп кую.*

Бүгенге кебек хәтеремдә – гыйлавәсен дә авыру хәлендә Тукай үзе язып бирде. (Тукайның бу мөсәүвәдәсе «Нур» идарәсендә саклана булырга тиеш.) Әйткәндәгесе шул булды:

– Дөрес, Садыйк  Иманколыйның  язганы  Муса әфәнде мәкаләсенә каршы сыек һәм дә бик сыек. Ләкин әдәп белгән кешеләргә Муса әфәнденең җөзафлыгын бик яхшы күрсәтә, – диде.

«Нур» идарәсендә утырган вакыт Тукайның тагын да бер язып китәргә ярый торган эше бар:

Башка газета идарәләрендә булган кебек, «Нур» идарәсенә дә бик күп шигырьләр килә иде. Мин шуларның арасыннан «өмидлерәк» дип уйланган берсен алып начар булса да, алда бер нәрсә чыгу өмиде илә, еш-еш газетага керткәли идем. Бервакыт Хәбибрахман Әлмөхәммәдов 3 исемендә берсе (Тозтүбәдән җибәрелә иде) нең бер шигыре астына идарәдән дүрт-биш юл сүз арттырып, ул кешедә шагыйрьлек чаткысы булганлыгын да гыйлавә кыйлган идем.

*Ризаләт – әшәкелек, түбәнлек.*
*Җәрех кыйлып – юкка чыгарып.*
*Бәгъзе  гыйбарәләрнең щөзафлыгын – кайбер  текстларның  уйламыйча язылганлыгын.*
*Хәмел кыйлалар – йөклиләр, аударалар.*
*Тәкъвия кыйлды – куәтләде.*
*Гыйлавәсен – кушымтасын, өстәмәсен.*
*Мөсәүвәдәсе – караламасы.*
*Җезафлыгын – лаф оруын, үлчәүсез сөйләвен.*

Сафа әфәнде Тукайга шул кешенең берничә шигырен күрсәтте. Бу шигырьләр басылмаска дип хөкем кыйлынган шигырьләр иде. Тукай карап утырды-утырды да үзенчә берсен кертергә ярый торган итеп тапты. Баштагы ике мисрагын үзгәртеп, ахырындагы бер сүзен алмаштырды да: басарга кирәк, диде. Аңа каршы мин ул шигырьнең мөндәриҗәсендә коры пессимистлык (коры бер өмитсезлек) тән башка бернәрсә дә булмаганлыгын бәян иттем. Шул вакыт ул миңа шулай җавап кайтарды:

– Бернәрсә дә юк бит инде... Шулай да әһәмияте бар. Пусть халык башымыздан кичердекемез көннәрнең өмидсез-кара көннәр икәнен белеп калсын... Аның характерный (табигый) ягы шул: бу көн кулына чак каләм тота белгән татар балаларының бары да шул өмидсезлек җырларын җырларга мәҗбүрләр... Менә шул хәзер матбугатта бик нык сизелеп калырга тиеш...

IX

Номерга чыгып ун көн торганнан соң, Петербург һавасының һич төзәлмәгәнен күргәч, Тукай Петербургтан китәргә булды. Китәсе көннең элекке көнендә Сафа әфәнденең Мойкадагы квартирында (мәсҗед янында) завтрак итте. Завтрактан соң мәктәптә укыган

балаларның үзен күрергә теләгәнлекләрен белдергәч, Тукай мәктәпнең арт ягына чыкты. Бу мәктәптә ир вә кызлар бергә укыйлар. Балалар янына керергә никадәр тәклиф ителсә дә, күндереп булмады. Бөтен җан азыклары Тукай шигырьләреннән гыйбарәт булган бу кечкенә мәктәп җәмәгатенә Тукайның мәктәп ягына чыгу ихтималы әйтелгән, балалар да бик куанганнар иде. Тукай чыкмагач, бик мәэюс булдылар. Тукай күрше бүлмәгә кергәч, мөгаллим әфәнде балаларына Тукайның «Аллаһе тәбарәкә вә тәгалә» шигырене укырга әмер итте. Башлап ир балалар хор булып, яшь, саф бер аваз белән дөнья күчереп мәзкүр шигырьне укыдылар. Алар артыннан кызлар хоры тагын да күңелле, тагын да матуррак иттереп «Тәэссер» вә «И туган тел» шигырьләрен укыдылар.

*Мисраг – шигырь юлы.*
*Мөндәриҗә – эчтәлек.*
*Тәклиф ителсә дә – кушылса да.*
*Мәэюс булдылар – өметсезләнделәр*

Бу вакыт балаларның никадәр шатланган-лыкларын тел белән дә, каләм белән дә тасвир мөмкин түгел.

Китәсе көн бу мәктәптә укыган бөтен ир вә кыз балалар исеменнән Тукайга (номерына) алты кешелек бер вәкаләт җибәрелде. Вәкилләрдән өчесе кыз, икесе ир бала, берсе мөгаллим Мәхмүт әфәнде Сипаев иде. Вәкилләр сөекле шагыйрьләренә үзләренең «сау булуларыны әйтеп, кыз балалар исеменнән мәгъсум мәхәббәт галәмәте булган зур бер букет – саф аллы гөлчәчәген тәкъдим иттеләр. Ир балалар исеменнән бронзадан эшләнгән яхшы, кыйммәтле бер карасавыт китерелгән, анда сәдакать вә мәхәббәт галәмәтен мөшгыйрь бер рәсем (эмблема) куелган–бронзадан бик матур бер үрдәк эте белән сумка сурәте төшерелгән иде. Тукай бу шәкертләрнең үзләренә дә, бүләкләренә дә бик куанып калды. Шәкертләр киткәч, өстәлне карават янына китереп, бик озак карасавыт өстендәге эт белән сабыйлар кебек шаярып ятты. Моңа кадәр беркем тарафыннан да мондый илтифат күрмәгән Тукайга бу бүләк вә бу илтифатлар бар да кызык тоелалар иде.

Карасавытның шундый эмблема белән сайлануы иттифакый түгел. Алдан уйланып куелган иде. Зур бер көч белән табылды. Тукайның һәрвакыт теленнән төшерми сөйли торган: «Кая ул кәкре койрыкларга Башны җитәргә!..»4 дигән бер сүзе бар иде. Бу сүз башта Казанның Печән базарындагы бер такым үткән-сүткән-дә сүз кушып кала торган иске татарларга каратып әйтелгән, соңыннан «Печән базары яхуд яңа Кисекбаш» китабына да кергән иде. Петербургта да номерга чыккач, Тукай бу сүзләрне бик тәкрар әйтте... Өши башласа, караватка менеп бөрешеп ята да:

– Кая ул кәкре койрыкларга Башны җитәргә! – ди иде. Менә шул «кәкре койрыклар» сүзен һәрвакыт исенә төшереп, Тукайга бер мәшгулият (әйләнҗә) бирү өчен, бүләккә шундый бер нәрсә һәм дә аның гомерендә бетми торган бер нәрсә алып бирергә мәслихәт күрелде.

*Вәкаләт – делегация.*
*Мәгъсум – эчкерсез, гөнаһсыз.*
*Сәдакать – турылык.*
*Мөшгыйрь – белдерүче.*

*Такым – төркем.*
*Мәшгулият – шөгыльләнү, мавыгу.*

«Китап» аның хакында бик яхшы әйтмәсә дә, сәдакать вә мәхәббәт хисе белән мемтаз булган эт сурәтенең бик яхшы бер эмблема булуы да игътибарга алынды. Киткәнче Тукай шул «кәкре койрыклар» белән мәшгуль булды. Шунлыктан мәктәп мөдриятенең бу бүләкне ихтыяр итүендә исабәт кыйлганлыгы күренде.

Кич белән Петербургта төрле тиҗарәтханә вә сәүдә йортларында хезмәт итүче приказчик вә сәүдәгәрләрдән 30–40 кеше бергә җыелып, Тукайга озату мәҗлесе ясадылар. Бу кешеләрдән берничәсе Тукайны номерга чыккач та чакырганнар иде, авырулык сәбәпле Тукай бара алмаган иде. Ахырдан барлыгы бергә җыелып, авыру шагыйрьләрен бер генә мәртәбә «мәшәкатьләргә» булдылар. Бу мәҗлес Петербургтагы бөек тиҗарәтханәләрдән берендә хезмәт итә торган Мөхәммәтшаһ әфәнде Җиһаншин квартирында булды. Мәҗлестә приказчик вә сәүдәгәрләрдән башка яшьләрдән Шакир Мөхәммәдьяров, Кәрим Сәгыйдов, берничә Петербург мөгаллимнәре, Муса вә Лотфи әфәнделәр дә бар иделәр. Тукай мондый мәҗлесләрне яратмый (өйрәнмәгән) иде. Шунлыктан мәҗлеснең аңа тигән ягы яхшы ук күңелсез үтте. Бу мәҗлестә сөйләнгән сүзләрнең күбесе Тукайның сәламәтләнеп, яңадан бик һәйбәт бер вакытта Петербургка килеп, кунак булырга тиешлеге хакында булды. Бу халык Тукайга юк өчен ихлас тотмаган, кайсының угылы, кайсының кызы бар, боларның мәктәптә иң яратып укыган китаплары Тукаев әсәрләре, Тукаев шигырьләре идеке мәгълүм. Мәҗлестә булганнардан бере үзенең ун яшьлек бер баласының Тукайны белгәнлеген сөйләде. Тукаев килгән дигәч, бу бала анасына Тукайны шулай тәгьриф кыйлган:

*Мөмтаз булган – аерылып торган.*
*Мөдриятенең – дирекциясенең.*
*Исабәт – төзәлгән урынга тидерү.*
*Тиҗарэтханә – кибет.*
*Тәгърифф – аңлату.*

– Ул элек минем шикелле кечкенә бер Апуш булган, шуннан соң «зуп-зуп Тукай» булган, – дигән. Бу сүзләрне сөйләгән вакыт мәҗлес никадәр зчпошыргыч булырга тиеш булса да – күңелле иде. Бердәнбер әсәрләре халык арасында күп файдаланылган бу яшь шагыйрьнең болай авырып китүенә мәҗлестә булган кешеләрнең һәркаюысы чын күңелдән кайгырыштылар.Бик «мужик» кешеләрнең дә шактый мөтәәсир булганлыклары күренде.

– Монда җыелган халыкның Тукайдан зур, мәһабәт бер кыяфәт белән гел генә хәкийми вә фәлсәфи сүзләр сөйләвен көтеп тә, алларында гаять дәрәҗәдә тәкәллефсез – садә бер яшь бала утырганы күргәч «тәсмигы бил Могайди...» 5 кабиленнән булмаса ярар иде дип утырган безгә дә бу мәҗлес бик яхшы тәэсир калдырды. Шул тәэсир белән бу хакта: безнең халыкта аз да булса «мән кал»дан узып «ма кал»гә йөз тоткан күренә башлады, дип «Йолдыз»да бер мәкалә дә басылган иде. Бүген вафатыннан соң елы үтеп тә, яхшы гына кешеләремез арасында Тукайга һәнүз «малай» күзе белән карау бетмәгәнлекне

күргәч, мин ул Петербург приказчикларының илтифатларын тагын да тирәнрәк тәкъдир итә башладым.

Мәҗлес ахырында шул мәҗлесне ясаучы приказчиклар исеменнән Тукайга адрес тәкъдим ителде. Конверт эчендә 50 сум акча да бар иде.

XI

Хәтеремдә ялгыш калмаган булса, поезд Николаевский вокзалдан төнге сәгать беренче яртыда кузгалачак иде. Вокзалда Тукайны озатырга Петербург имамнарыннан Сафа ахунд Баязитов, Лотфи әфәнде Исхаков, төрле мәктәпләрдә укучы студент вә яшьләр, төрле сәүдә йортларында хезмәт итүче мөселман приказчиклары да килгәннәр – 25–30 га якын кеше бар иде. Мәҗлес алдыннан сөйләнгән сүз буенча тимер юлга билетны Уфага кадәр Муса әфәнделәр алып куярга тиеш иделәр. Көндез бервакыт Муса әфәнде, Тукай янына кереп, үзе билет алып куячагын әйтеп киткән иде. Шунлыктан башкалар билетны Муса әфәнде алган дип тордылар.

*Мөтәэссир – тәэсирләнү.*

Хәлбуки Муса әфәнде вокзалга да килмәде. Поезд китәр вакыт якынлашкачтан, Сафа әфәнде белән мәслихәтләшеп, без өченче класстан плацкарт белән бер билет алдырдык. (Каты йөткергәнлектән, икенче класс кешеләре белән килешеп барырга уңгансыз булыр, дип Тукай икенче класстан билет алырга риза булмады. Ятыр өчен аерым урынлы булгач, өченче класс та ярар, диде.)

Икенче, өченче звонок булды. Муса әфәнде һәнүз юк иде. Тулып торган халык арасыннан ерып кереп утырып та өлгермәдек – поезд кузгалып та китте.

Мин Тукайны Мәскәүгә кадәр озата киттем. Иртәсекөн сәгать 10 нарда Мәскәүгә җиттек. Анда Николаевский вокзалдан Рязащжий вокзалга күчеп, аш (обед)ашап, чәй эчүгә, поезд килде. Бик сайлап бер урын алып, Тукайны утыртып озатып калдым. Мәрхүм, ялгыз китәргә булгач, бик уңгайсызланраң кебек булган иде. Уфадан язган хатында бик яхшы кайтканлыгын белдерде.